**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631д.Дятлово ,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАМА КОМИТЕТЫ**
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

**2023 елның 11 декабре** **13 номер**

**КАРАР**

**Рождествено авыл җирлеге территориясендә пиротехника эшләнмәләрен куллану урыннары турында**

Яңа ел бәйрәм чараларын үткәрү вакытында, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затларның, дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясына һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына таянып, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру турында»карарларга нигезләнеп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Билгеләргә:
   2023 елның 20 декабреннән 2024 елның 10 гыйнварына кадәр Рождествено авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим;
2. Махсус янгынга каршы режим чорында 1-3 класслы хәвефлелектәге пиротехник эшләнмәләрдән (бенгаль утларыннан, мамык кисәкләреннән тыш) файдалануны тыярга:
   Сәнәгать объектлары, транспорт инфраструктурасы (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линия)чикләреннән 500 метр ераклыкта,
   Торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күпләп булган объектлар, автомобиль юллары, шәхси йортлар чикләреннән 30 метр; күп фатирлы торак йортлардан 30 метр ераклыкта.

3. Рождествено авыл җирлеге гражданнарына пиротехниканы куллану өчен 4 урын билгеләргә

- Рождествено авылы, Үзәк урам, Меша елгасы сулыклары

- Дятлово авылы, Яшел урам, Дятлово торак пункты чигеннән көньяк-көнчыгышка таба 500 метр

Тангачи авылы, Яңа урамы, Сарапкин О.Н. КФХдан көньяк-көнчыгышка таба 500

метр.

- Сингели авылы, Клуб урамы, Казан-Атабай трассасыннан көньяк-көнчыгышка таба 500 метр

4. Әлеге карарны Рождествено авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларынбашкаручы** **С.М. Гуцу**